**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл җирлегенә керүче Тарханка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2019 елның 18 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегенең Тарханка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Аксубай муниципаль районының Иске Илдерәк авыл җирлеге Тарханка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм студентлардан тыш, 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тарханка торак пунктында кышкы чорда бистә эчендәге автомобиль юлларын карап тоту;
- Тарханка авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау, ком һәм вак таш салу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: htt: //pravo.tatarstan.ru.

Иске Ильдеряк авыл җирлеге башлыгы: В. К. Әлмәткин